КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 сентябрь г.Казань № 966

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карары белән расланган Тиешле рөхсәтсез сакланган яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз иреге белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләк бирү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 15 ноябрь, 832 нче; 2002 ел, 25 октябрь, 625 нче; 2003 ел, 4 апрель, 179 нчы; 2004 ел, 17 май, 239 нчы; 2008 ел,

2 октябрь, 724 нче; 2010 ел, 17 август, 661 нче; 2016 ел, 31 март, 192 нче; 2016 ел, 13 сентябрь, 638 нче; 2019 ел, 1 апрель, 255 нче; 2020 ел, 21 август, 717 нче; 2020 ел, 28 декабрь, 1209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Тиешле рөхсәтсез сакланган яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз ирекe белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләк бирү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацта «түбәндәгеләрне теркәп, акчалата бүләкләү түләү турында гариза (алга таба – гариза) белән Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Күпфункцияле үзәк) яки аның филиалына мөрәҗәгать итә:» сүзләрен «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Күпфункцияле үзәк) аша яки башка ысул белән, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәләре порталлыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм (яисә) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карарында рәсмиләштерү тәртибе билгеләнгән, түбәндәгеләр теркәлгән акчалата бүләкләү түләү турында гариза (алга таба – гариза) бирә:» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «ачылган счет реквизитларын» сүзләрен «ачылган счет реквизитлары бирелгән документны» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Күпфункцияле үзәккә» сүзләреннән соң «яки башка ысул белән» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта «Күпфункцияле үзәктән» сүзләреннән соң «яки башка ысул белән» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин